КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 9 февраль г.Казань № 85

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгамәлә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 июнь, 502 нче; 2022 ел, 11 март, 217 нче; 2022 ел, 9 август, 780 нче; 2022 ел, 6 декабрь, 1292 нче; 2023 ел, 9 июнь, 705 нче; 2024 ел, 7 май, 305 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1279 нчы; 2025 ел, 14 июль, 513 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгамәлә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта:

«е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) хайваннарны вакытлыча тоту пунктларында хуҗасыз хайваннарны тоту;»;

түбәндәге эчтәлекле «ж» һәм «з» пунктчаларын өстәргә:

«ж) «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^2$ статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән очракларда хуҗасыз хайваннарны үтерү;

з) 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләре нигезендә кирәкле башка чаралар.»;

III бүлектә:

исемендә «хайваннар өчен приютларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хайваннар өчен приют җитәкчесенең карары буенча хайваннар өчен приютның карантин бүлмәсенә кабул ителгән хуҗасыз хайваннар мотивсыз агрессия булуга (булмауга) карата тикшерелергә мөмкин.

Мотивсыз агрессия булган очракта, хайваннар өчен приют җитәкчесенең карары буенча хуҗасыз хайваннар вакытлыча карап тоту пунктына күчерелергә мөмкин.»;

3.7 пунктка «(әлеге Тәртипнең 3.5 пунктындагы өченче абзацында каралган очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

3.9 пунктка «(әлеге Тәртипнең 3.5 пунктындагы өченче абзацында каралган очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

3.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.13. Хайваннарны вакытлыча тоту пунктларында хуҗасыз хайваннарны тоту рөхсәт ителә.»;

3.24 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хайваннарны вакытлыча тоту пунктларында тотыла торган хуҗасыз хайваннарны үтерү («Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^2$ статьясындагы 2 өлешендә каралган очраклардан тыш) тыела.»;

Әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасында «хуҗасына тапшыру,» сүзләреннән соң «хайваннарны вакытлыча тоту пунктына тапшыру,» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибен һәм хайваннарны тоту нормаларын раслау турында» 2020 ел, 28 февраль, 150 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 декабрь, 1292 нче; 2025 ел, 2 июль, 480 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибенә һәм хайваннарны тоту нормаларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хайваннарны вакытлыча тоту пунктында һәм хайваннар өчен приютта хайваннарны, шул исәптән хуҗасыз хайваннарны аерым тотуны һәм исәпкә алуны тәэмин итү шарты белән хайваннар өчен приют территориясендә хайваннарны вакытлыча тоту пункты урнаштыру рөхсәт ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.5^1$ пункт өстәргә:

«$2.5^1$. Хайваннарны вакытлыча тоту пункты эшчәнлеген оештырганда әлеге Тәртипнең 2.5 пунктындагы өченче – бишенче абзацларында күрсәтелгән биналарны, корылмаларны һәм бүлмәләрне куллану рөхсәт ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин